

Мордовия Дәvләт Жыелышы рәисе Владимир Чибиркин яна составлы республика Ижтимагый палатасынын беренче утырышында катнашты.
«Жәмәгать палатасы - безнен жәмгыятьтә моһим институт. Анын топ бурычы-хакимият органнары һәм гади гражданнар арасында диалог. Яна состав моны югары профессиональ дәрәжәдә дәвам итәр дип ышанам», – дип билгеләп vтте Мордовия башлыгы Артём Здунов. Тобәк житәкчесе палатанын яшьләр, дини, ветераннар оешмалары белән ана һәм балачак, мәдәният һәм тарих мәсьәләләре буенча моһим эшен атады. Топ темаларнын берсе – СВО әгъзаларын һәм аларнын гаилә әгъзаларын реабилитацияләv һәм адаптацияләv. Яна составнын Ижтимагый палатасында 51 жәмәгать эшлеклесе, шул исәптән Мордовия Дәvләт Жыелышы тарафыннан расланган 17 кеше эшләячәк. Депутатлар ижтимагый оешма вәкилләре белән актив хезмәттәшлек итәләр, аларнын тобәкнен социаль-икътисади vсеше мәсьәләләрен хәл итvдә катнашуын моһим дип саныйлар. Бу хакта Дәvләт Жыелышы рәисе Владимир Чибиркин әйтте.

Мордовия Республикасы Дәvләт Жыелышы депутаты, Пензятка урта мәктәбе директоры Надия Харис кызы Заликова югарыда әйтеп киткән бурычларны тормышка ашышып килә. Шулай, без Пензятка авылы почтасын, тулы кvләмдә эшләv очен шартлар булдыру буенча керткән олеше турында, авыл урамнарындагы яктылык, юл мәсьәләре һәм башкаларынын хәл ителvе турында беләбез. Бvгенге кондә, депутат буларак, Пензятка

авылы халкы сорауларын, булдыра алган кадәр vзе чишәргә ярдәм итә, ә зур мәсьәләрне чишv очен югары инстанцияләргә морәжәгать итә. Шулай, букадәр эссе жәйдә суы булмаган якташына су жибәртергә ярдәм итә надия Харис кызы, социаль тvләvләрне тиешенчә алу буенча Ләмберә социаль яклау хезмәткәрләре белән элемтәгә керә. Пенсион фондка барыр очен транспорт табу да олы яшьтәге кешеләргә зур ярдәм – моны да хәл итә ул.
Әңгәмәбез вакытында Пензятка урта мәктәбе директоры Надия Харис кызы Заликовага мәктәп эшләре турында сорау бирми булдыра алмадым. Ләмберә региональ сайлау округы буенча Мордовия Республикасы Дәvләт Жыелышы депутаты Надия Харис кызы соравыма жавабында шулай диде:
- Хәзерге вакытта мәктәпне, яна уку елын тиешенчә каршы алу очен, бар эшләрне башкарып киләбез. Барлыгы 2024-25 уку елында Пензятка урта мәктәбендә 128 укучы белем алачак; аларнын 17 – беренче сыйныфка, ә 5 – 10 сыйныфка киләләр. Аларга унай шартлар булдыру остендә эшлибез. Шулай, vз кочебез белән, ата-аналар ярдәме белән мәктәп бинасына косметический ремонт ясыйбыз. Активларны да әйтеп китәргә кирәк, бу - Власова Наталья Павловна (ата-аналар комитеты житәкчесе), Кадикина Алена Рафик кызы һәм башкалар. Мәктәп участогын, территориясен, чәчәкләренә кадәр хезмәт таләп итәләр – барысына да житешәбез.

**Наилә НАСЫРОВА**